# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Майна авыл җирлеге» Баганалы урман хуҗалыгы торак пунктында

2024 елның 12 апреленнән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Майна авыл җирлеге» Баганалы урман хуҗалыгы торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлегенең Баганалы урман хуҗалыгы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 13 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

2) тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

3) ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

2.Әлеге карарны Майна авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге башлыгы Я.Д.Иванов